| ГЛАВА МОЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛКИ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**16.11.2024ел.** **Мәлки авылы** **№ 5**

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Мәлки авыл җирлегенең
Мәлки авылында гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗномерлы Федераль законының 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 26 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Мәлки авылы, Лесная урамы, 52 нче йорт адресы буенча урнашкан Мәлки төп гомуми белем бирү мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегендә үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2024 елның 27 ноябрендә 11 сәгать 30 минутта Мәлки авылы, Молодежная урамы, 2 нче йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Мәлки авылында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2024 елның 28 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Мәлки авылы, Гагарин урамы, 5 нче йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Мәлки авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. 2024 елның 29 ноябрендә 13 сәгать 30 минутта Мәлки авылы, Почта урамы, 18 адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәк бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Мәлки

авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- су белән тәэмин итү, чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- традицион күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, төзекләндерү;
- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.»

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны Мәлки авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка таратырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Мәлки авыл җирлеге Башлыгы Ф.П.Поляков